**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**МАЛОКИБЯКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Малая, 10, село Малые Кибя-Кози,
422080
тел. (факс): (884360) 56-2-49
E-mail: **Mbiz.Tul @tatar.ru**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЕЧЕ КИБӘХУҖА**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кече урам, 10, Кече Кибәхуҗа авылы,
422080
тел. (факс): (884360) 56-2-49
E-mail: Mbiz.Tul @tatar.ru

ОКПО 94318079 ОГРН 1061675010451 ИНН/КПП 1619004429/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№4**

**КАРАР**
**22 января 2024г**

## 2024-2028 елларга шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның яңа хуҗалык кенәгәләрен булдыру һәм алып бару турында

«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 07 июлендәге 112-ФЗ номерлы, «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Хуҗалык кенәгәләрен алып бару рәвешен һәм тәртибен раслау турында» 2022 елның 27 сентябрендәге 629 номерлы боерыгы нигезендә һәм Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу максатларында, Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге территориясендә 2024-2028 елларга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең бухгалтерлык һәм махсуслаштырылган хисапларын җыю һәм эшкәртүнең комплекслы мәгълүмати системасын, агросәнәгать комплексына ярдәм итүгә субсидияләрне формалаштыру, мониторинглау, исәпкә алу, контроль һәм анализлауның комплекслы мәгълүмати системасын кулланып электрон формада биш елга шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның яңа хуҗалык китапларын булдыруны оештырырга.

2. Ел саен, 1 гыйнварга торыш буенча, шәхси ярдәмче хуҗалыкларны тоташ йөреп чыгып һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны сораштырып 10 гыйнвардан 15 февральгә кадәр чорда кенәгәләрдә күрсәтелгән белешмәләр җыюны гамәлгә ашырырга.

3. Хуҗалык кенәгәләренә язмаларны үз ихтыяры белән шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгы яисә шәхси ярдәмче хуҗалыкның башка әгъзалары тарафыннан бирелә торган белешмәләр нигезендә теркәргә.

4. Хуҗалык кенәгәләрен алып барганда, хуҗалык алып баручы гражданнар тарафыннан бирелә торган мәгълүматның конфиденциальлеген, аның сакланышын һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә яклауны тәэмин итәргә кирәк.

5. Хуҗалык кенәгәләрен тиешле тәртиптә алып бару һәм аларның сакланышы өчен җаваплы итеп түбәндәгеләрне билгеләргә:

- Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре Мөхәммәтҗанова Г.И.;

- Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты бухгалтеры Даутова И.В.

6. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Теләче муниципаль районының рәсми сайтында Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

7. Карар 2024 елның 22 гыйнварыннан үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.Г.Заһидуллин